ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.01.2019 г. Агрыз № 1

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 27 июнендәге 28-2 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны 2019 елның 4 февралендә 09.30 сәгатьтә муниципаль берәмлек Башкарма комитетының актлар залында уздырырга: ТР, Әгерҗе ш., Гагарин ур., 13 й.

3. Проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча җибәрелә дип билгеләргә: ТР, Әгерҗе ш., Гагарин ур., 13 йорт, 16нчы кабинет.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проектын Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН СОВЕТ ... ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ... Общий отдел Гомуми бүлек

**В.В. МАКАРОВ**

Башкаручы:
Л.С. Барекова